СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2024 г.Лениногорск № 84

Лениногорск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 19 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Лениногорск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында гражданнарның муниципаль хезмәттән тигез файдалану өлешендә муниципаль хезмәтнең төп принципларын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Уставына таянып, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 19 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 пунктның «а» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече һәм өлкән төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләп куелганда җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы
урынбасары

С.В.Тимаков